| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕПОДБЕРЕЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ПОДБЕРЕЗЬЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**22.11.2024 г** Олы Подберезье ав. № 7

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге территориясендә кыргый наркотиклы үсемлекләр үсү чыганакларын ачыклау һәм юкка чыгару чаралары турында» 2023 елның 05 июлендәге 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге территориясендә кыргый наркотиклы үсемлекләр үсү чыганакларын ачыклау һәм юкка чыгару чаралары турында» 2023 елның 05 июлендәге 6 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.6. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6. Эш төркеменең составы 5 кешедән тора. Эш төркеме утырышы, әгәр анда әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, хокуклы дип санала.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә https://bpberez-kaybici.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http//pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе О.М.Емельянова

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ Большеподберезинского сельского поселения